КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 август г.Казань № 648

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту турында» 2008 ел, 15 июль, 509 нчы карары белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту турында» 2008 ел, 15 июль, 509 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 27 ноябрь, 922 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту тәртибенә, 4.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4.13. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлегенә планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү турында, аларның нәтиҗәләре турында һәм ачыкланган тәртип бозулар, аларны булдырмау һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерү буенча күрелгән чаралар турында Россия Федерациясе

Хөкүмәте раслаган тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм аны алып бару кагыйдәләре нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиеш.».

2. Бу карар 2018 елның 19 августыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин